**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» сентябрь 2021 ел № 211

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ өчен «Микулино авылы янында Ямашка елгасында нефть тоту корылмасын төзү» объектын проектлау өчен Микулино авыл җирлеге чикләрендә Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру һәм аны ызанлау проектларын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә, «Стройпроектнадзор» ҖЧҖ тәкъдимен карап, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатында, карар бирә:

1. «Стройпроектнадзор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге чикләрендә В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ өчен «Микулино авылы янында Ямашка елгасында нефть тоту корылмасын төзү» объекты өчен үз акчалары хисабына территорияне планлаштыру проектының һәм территорияне ызанлау проекты турындагы тәтәкъдимен кабул итәргә.

2. Физик һәм юридик затларның территорияне планлаштыру документларының тәртибе, аларны әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен карау өчен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә җибәрергә. Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турындагы тәкъдимнәрне караганда әлеге тәкъдимнәрне керткән физик һәм юридик затларны чакыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары
Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов